РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Асеевского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района
ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әсәй авыл җирлеге
Башлыгы
Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы,
Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» октябрь 2025 ел. № 2

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 2025 елның 05 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. 2025 елның 05 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын, Тукай урамыннан 1нче йорттан 53нче йортка кадәр, Тау асты урамыннан нче йорттан 2 нче йортка кадәр, Мәктәп урамыннан 1нче йорттан 18 нче йортка кадәр сайлау хокукына ия булган һәм Митрәй авылында теркәлгән гражданнар өчен билгеләргә.

3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитеты;

– Халык җыенының беренче һәм икенче этапларын үткәрү урыны-Митрәй авылы, Тукай ур., 15а йорт, Митрәй авылы мәдәният йорты залы.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- Митрәй торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Митрәй торак пункты халкына гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

" Сез, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең Митрәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 400 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучылардан тыш үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1). Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр, Тукай, Тау асты, Мәктәп урамнарындагы вак таш юлларны профильләштерү, тыгызлау);

2). Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җайланмалар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алмаштыру)тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3). Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (триммер һәм трактор өчен запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу, үлән чаптыру, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Әлеге карарны адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- Азнакай районы, Митрәй ав., Тукай ур., 15А.;

- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru,

- кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Башлык Г.З. Дәминова